КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 март г.Казань № 217

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 702 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Хуҗалары булмаган, тотып алынган хайваннарны стерилизацияләү (кастрацияләү) һәм аларны котыру авыруыннан вакцинацияләү ветеринария (хирургия) ярдәме күрсәтү өчен билгеләнгән махсус урында (бинада, корылмада), хайваннар приютында яисә, хуҗалары булмаган этләрнең карантин бүлмәләрендә булу вакыты чыкканнан соң, ветеринария өлкәсендәге белгеч тарафыннан

билгеләнә торган ветеринария күрсәткечләрен исәпкә алып, ветеринария оешмасында (клиникасында) башкарыла. Әлеге процедура, асептика һәм антисептика, авыртусызландыру кагыйдәләрен саклап, гуманлы ысул белән башкарыла.»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Элекке яшәү урынына, хайваннар приютында хуҗалары булмаган хайваннарга карата карантинда тоту, дәвалау, вакцинация, стерилизация (кастрация) ясау, тамга салу чаралары тәмамланганнан соң, әлеге мотивлаштырылмаган агрессивлыгын күрсәтми торган хайваннар кире кайтарылырга тиеш. Хуҗалары булмаган хайваннарның мотивлаштырылмаган агрессивлыгы булуы йә булмавы турында карар (алга таба – карар) хайваннар приюты җитәкчесеннән һәм аның ике хезмәткәреннән торган комиссия тарафыннан кабул ителә. Комиссия карары ирекле формада язылган ветеринария бәяләмәсен төзү юлы белән рәсмиләштерелә.»;

әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтада «үтерү» сүзеннән соң «, табигый үлем» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин